ЮГАЛМАСЫН АКЧА

Хөкүмәт йортында керемнәрне һәм чыгымнарны санадылар

> 2

ХӘЗРӘТ АВЫЛЫ

Бөрбашта 40 ел элек төзелгән мәдәният йортын яңарттылар

> 3

АЛКА КЕРМИ

«Ак барс» октябрьдә 12 очрашуның Зесендә генә җиңә алды. Ни өчен?

> 4

КАЛӘМ КИЧӘСЕ

Хезмәттәшебез Камил Сәгъдәтшин берьюлы ике бәйрәм ясады

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 161 (28934) | Сишәмбе | 1 ноябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Сәрия МИФТАХОВА

СОЛДАТКА КИТКӘНЧЕ

Киләсе уку елыннан укучыларны хәрби әзерлеккә өйрәтә башламагайлары. Аерым фән итеп түгел, Тормыш иминлеге нигезләре (ТИН), ягъни ОБЖ дәресләрендә. Хәзерге вакытта аны яңа федераль белем бирү стандартларына кертү турында сүз бара. Әлеге сәгатьләр егетләрнең солдатка әзерлеген, илне саклау теләген арттырырмы?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Октябрь аенда Дәүләт Думасы депутатлары Россия Мәгърифәт министры Сергей Кравцовка хәрби әзерлек дәресен мәктәпләргә кире кайтару тәкъдимен җиткергән иде. Депутатлар белдергәнчә, совет чорында укучыларга 60 ел буе әнә шундый фән укытылган. «Укытучылар – офицерлар. Алар белән укучылар автомат җыярга, противогаз киярга, беренче медицина ярдәме күрсәтергә, шулай ук илнең кораллы көчләре тарихын өйрәнделәр», – дип белдерә идея авторлары.

Бу эшне ТИН дәресендә оештырырга ниятлиләр. Бүген исә, тормышта иң кирәкле фән булса да, мәктәпләрдә аңа игътибар җитми. Әлеге дә баягы БДИга кирәкле фәннәр үзенекен итә. Тик укытучыдан да күп нәрсә тора. Кайберләре дәрес белән генә чикләнмичә, кызыксындыру юлларын таба белә.

– Югары сыйныфларда болай да хәрби әзерлек нигезләрен өйрәтәләр. Анда автомат сүтеп җыю, граната үзенчәлекләрен, тактик әзерлек, стройда йөрү тәртибен һәм башкасын өйрәтәбез. Тик атнага бер сәгать кенә җитми. Башка илләрдә кечкенә сыйныфтан ук моңа өйрәтә башлыйлар, – ди Балтач районындагы Иске Салавыч лицееның ТИН һәм физкультура укытучысы Ранил Гыйләҗев. – Егетләр генә түгел, кызлар да ТИНны якын итә. Спортзалда пневматик мылтыктан аталар. Февраль аенда оборона-спорт айлыгы үтә, «Аҗаган» уеннары уздырабыз. Анда җиңгән сыйныф Казанга бер көнлек экскурсиягә бара.

Татарстанның халык укытучысы, Биектау районының Дөбьяз мәктәбендә ТИН дәресеннән белем бирүче, «Булачак солдат» түгәрәге җитәкчесе Радик Җиһаншин заманында башлангыч хәрби әзерлек (НВП) дәресләрен укыткан. Шуңа күрә ул үткән белән бүгенгене чагыштыра ала.

– Армиядә бер ел хезмәт итү – бик аз ул. Мәктәптә алдан әзерләсәләр, бик әйбәт инде. «Кисәтелгән – саклангән», – дип әйтәләр бит. Армиягә белеп барганда, егетләргә хезмәт итү җиңелрәк була. Кайткач, рәхмәт әйтә иделәр миңа. Хәрби хезмәттә бирелгән характеристикаларын әле дә альбомда саклыйм. Хәрби әзерлек дәресләре элек атнага ике тапкыр керә иде. Хәзер дә тормыш иминлеге нигезләре кысасында бар ул. Әмма бик аз, күбрәк иминлеккә игътибар бирелә. Анда стройда йөрү, атарга өйрәтү, тактика… Элек исә дәресне армиядә солдатны «Яшь сугышчы» курсында өйрәткән кебек уздыра идек. Хастаханәдән табиб килеп, кызларга медицина буенча белем бирде, – ди Радик Җиһаншин.

Элеккеге армия белән хәзергесен дә чагыштырып: «Хәзергесе бик җиңел. Беренчедән, бер ел. Икенчедән, төшке аштан соң пионерлагерьдагы кебек бер сәгать йоклау… Шуңа күрә хәрби операция вакытында да аларга әзерлек җитми. Бер ел эчендә танк, ракетаны ничек өйрәнеп бетереп булсын?! Ике ел хезмәтне кертмәячәкләр, әлбәттә. Әмма моны дәресләрдә яхшылап өйрәтергә кирәк», – дигән фикердә ул.

Патриотик хисне дә мәктәпләрдә әләм күтәреп яки төшереп кенә арттырып булмый дип саный ул. «Атнага өч тапкыр «Булачак солдат» түгәрәгенә йөрүче укучыларымда бик көчле бу хис. «Юнармия» ярышларына йөриләр, шуның эчендә кайнашалар. Теория өйрәнеп, ватанпәрвәрләр тәрбияләп булмый», – ди Радик Җиһаншин.

Татарстан «Юнармия» хәрәкәте штабы башлыгы урынбасары Илһам Мидхәтовның да әлеге тәкъдимгә карата фикерен сораштык.

– Бүгенге ТИН дәресләре яшьләрне илне сакларга өйрәтми. Шуңа күрә элек булган башлангыч хәрби әзерлек фәнен мәктәпләргә кире кайтарырга кирәк. Атнага бер сәгать керә иде ул. Кызлар медицина белеме тупласа, егетләр Ватанны сакларга өйрәнде. 9 нчы сыйныфны тәмамлагач, биш көнлек кыр җыеннары үткәрелә иде. Басуда окоп казый идек, – дип искә ала Илһам Мидхәтов. – Хәрби әзерлек дәресләрен түгәрәк итеп кенә калдырырга ярамый. Мәҗбүри булмагач, анда балаларның барысы да йөрмәячәк. Бүген яшь буынга патриотик хисне әкренләп кайтарабыз. «Юнармия» хәрәкәтенең файдасы зур. Тик әлеге хәрәкәттә укучыларның 4 проценты, ягъни 34 меңе генә шөгыльләнә. Республикада исә 400 меңнән артык укучы бар. Кызыклы чаралар уздырабыз, бер-берсеннән күреп, башкалар да кызыгып язылa.

Ярамаган тагын дип, тормыш иминлеге дәресләренә башка фән укытучыларын билгеләгән мәктәпләр дә юк түгел.

– Мәктәптә укыганда 10 нчы сыйныфта гына ТИНне профильле белеме булган кеше укытты. Башка елларны дәрескә йә технология укытучысы, йә тагын башкасы керә иде. Һәм бу – безнең авыл мәктәбендә генә түгел, бөтен район буенча күзәтелгән хәл. Чыннан да, яхшы, белемле ТИН укытучысын табу авыр хәзер, – ди кичәге студент Ильяс Баһауов.

Аның фикеренчә, әгәр дә балаларны мәктәпләрдә хәрби әзерлеккә өйрәтә башлыйлар икән, димәк, ил сәясәте дөрес юлдан тайпылган. «Укучыларга, миңа калса, гуманлылык кыйммәтләрен төшендерергә кирәк. Һәм шул очракта гына киләчәк буын кулына корал тоту турында бөтенләй уйламаячак», – дигән фикердә ул.

Халык яза

Быел тугыз ай эчендә «Халык контроле»нә 74,4 мең хәбәр алынган. Узган елның шушы ук чорындагыга караганда 9 процентка артыграк бу. Территорияләрне төзекләндерү, юлларны ремонтлау мәсьәләләре буенча мөрәҗәгать итүчеләр аеруча күп. Татарстанда Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, төбәк белән идарә итү үзәге проект офисы рәисе Сәрия Сабурская әйтүенчә, 54 меңнән артыграк мөрәҗәгать (72%) уңай хәл ителгән. 4 меңе кире борылган. Кайберәүләр нигезсез таләпләр куя. Бигрәк тә бу юл билгеләрен урнаштыруга бәйле мөрәҗәгатьләргә кагыла.

Сәрия Сабурская әйтүенчә, халыкны иң еш борчый торган мәсьәләләр – территорияләрне төзекләндерү, юлларны карап тоту һәм төзекләндерү. Быел 40 меңнән артыграк шундый мөрәҗәгать кабул ителгән.

Хезмәт итә башлагач алалар

Татарстанның «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хезмәт итүчеләргә бер тапкыр түләнә торган акчаны бирү тәртибе үзгәртелгән. Хәзер алар Донецк, Луганск халык республикаларында, Херсон, Запорожье өлкәләрендә һәм Украинада хәрби хезмәтне башлап җибәргәч, 250 мең сум күләмендә акча алачак. Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин бу җәһәттән тиешле карарга кул куйган.

Моңа кадәр хәрби хезмәткәрләргә этаплап түләнгән: 60 мең сум күләмендә беренче түләү хәрби частьтагы исемлеккә кертелгәннән соң, калганы батальоннар Донецк, Луганск халык республикалары, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашу өчен дәүләт чиген узгач алынган.

Сигез ярминкә узган

10 сентябрьдән Татарстанда һәр шимбә саен ярминкә үткәрелә. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы хәбәренә караганда, көзгә кергәннән бирле узган сигез ярминкәдә барлыгы 820,7 миллион сумлык продукция сатылган. Тәгаенләп әйтсәк, 10774,9 тонна яшелчә, 7292,6 тонна бәрәңге, 825,6 тонна ит, 125,4 тонна сөт сатылган.

Исегезгә төшерәбез: шимбә ярминкәләре Казанның 14 мәйданчыгында, Чаллы һәм Яшел Үзәндә, Түбән Камада уздырыла. Моннан тыш алар әледән-әле 26 районда оештырылып килә.

tatarstan.ru

Яңалык

Ноябрь ае үзгәрешләре

Пенсияләр арта, компьютер программалары Россиянекенә күчерелә, чит илләргә уылдык чыгаруга чикләүләр кертелә. Бу айдагы иң мөһим үзгәрешләрне туплап, укучылар игътибарына тәкъдим итәбез.

ПЕНСИЯЛӘР АРТА

Күмер сәнәгате хезмәткәрләре һәм очучыларның пенсиясе артачак. Ләкин алар белгечлеге буенча эшен туктатырга тиеш. Акчаның күпмегә артасы эш стажы, хезмәт хакы күләме һәм предприятиеләре түләгән иминият кертемнәре күләменә бәйле. Әйтик, Новосибирск өлкәсендә очучыларның пенсиясенә – 21510 сум, Пермь краенда – 21891сум, шахтерларга – 4450 сум һәм 4021 сум өстәлә.

МОБИЛИЗАЦИЯЛӘНҮЧЕЛӘРГӘ ТҮЛӘҮЛӘР

Өлешчә мобилизациягә эләгүчеләр 1 ноябрьдән кимендә 195 мең сум акча ала башлаячак. Моннан тыш октябрьдә алар торак-коммуналь хезмәтләргә вакытында түләнелмәгән бурычларына пеня өстәлүдән азат ителде. Бу чара контракт тәмамланганчы гамәлдә булачак. Шул ук вакытта кайбер төбәкләр мондый ир-егетләрнең гаиләләренә «коммуналка» өчен түләүне өлешчә каплау теләген белдергән.

КӨЗГЕ ЧАКЫРЫЛЫШ

1 ноябрьдән көзге чакырылыш башлана. Ул, гадәттәгечә, 31 декабрьгә кадәр дәвам итәчәк. Быел чакырылыш 30 көнгә кыскарак – мобилизация сәбәпле, хәрби комиссариатларның эшен җиңеләйтү өчен, кампания бер айга кичектерелде. Вакытлыча хәрби хезмәткә 18дән 27 яшькә кадәрге 120 мең солдат китә. Бу узган елдагы көзге чакырылыштан 7,5 мең кешегә кимрәк. Чакырылыштан тәүге тапкыр IT өлкә хезмәткәрләре азат ителә. Хакимияттәгеләр ышандырып әйткәнчә, солдатлар Донецк, Луганск халык республикаларына, Запорожье, Херсон өлкәләренә җибәрелмәячәк һәм Украинада махсус хәрби операциядә катнашмаячак.

РОССИЯ ПРОГРАММАЛАРЫНА КҮЧҮ

Бу айда дәүләт органнарын Россиянең компьютер программаларына күчерү башлана. Яңалык иң элек Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр, Эчке эшләр министрлыкларына һәм Росреестрга кертелә. Калган хакимият органнары, дәүләт корпорацияләре, оешмалар һәм кешеләр бу эшкә үзләре теләп кушылырга мөмкин. Моның өчен киләсе елның 1 апреленә кадәр гариза тапшырырга кирәк. 2025 елдан дәүләт хакимияте органнарына чит илләрнең программаларыннан файдалану тыелачак.

УЫЛДЫК ЧЫГАРУ ТЫЕЛА

Ноябрьдән Камчаткада самолет белән кызыл уылдыкны чит илгә чыгаруны чикләү кертелә. Июль аенда кабул ителгән закон нигезендә, самолет пассажиры чит илгә күп дигәндә 10 килограмм уылдык алып чыгарга мөмкин. Су байлыкларын саклау һәм аларның законсыз әйләнешен кисәтүгә юнәлдерелгән эш 2025 елның 1 августына кадәр дәвам итәчәк.

ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНАТЫНА КЕРТӘЧӘКЛӘР

Катар хакимияте (анда 20 ноябрьдән 18 декабрьгә кадәр футбол буенча дөнья чемпионаты узачак) чит ил, шулай ук Россия туристлары өчен COVID-19 буенча барлык чикләүләрне бетерә. Дөрес, чемпионат вакытында туристлар Hayya card белән генә керә ала. Уенга билетлары булган кешеләргә бирелә торган җанатар паспортына охшаш документ бу.

Сүзгә-сүз

Ринат МӨХӘММӘДИЕВ, язучы, Тукай премиясе иясе:

Без искиткеч катлаулы дәвердә яшибез, күп кешеләр бүгенге көннең катлаулылыгын аңлап бетерә алмый. Безнең матбугат, әдәбият бу мәсьәләгә битарафрак карый кебек. Халыкны күптән әзерләргә кирәк иде. Халыкта патриотик хис булырга тиеш, әмма әлегә «минем йорт читтә» дигән кебек яшәүчеләр күп. Чынлыкта хәл киеренке. Халыкка түземлек телисе килә.

(«Интертат»ка әңгәмәсеннән)

МИЛЛИ АШ БӘЯСЕ

Татарстанның Милли банк белгечләре, Росстат мәгълүматларына таянып, татар милли ашларын әзерләүнең күпмегә төшкәнен исәпләп чыгарган. Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда бәяләр ничек үзгәргән икән?

+9,0% >> өй ризыклары пешерү өчен тотыла торган азык-төлек бәясенең еллык үсеше

Юмарт республика

Быел республикада барлыгы 1,4 мең тоннага якын гошер сәдакасы җыелды. Бу – рекордлы күрсәткеч. Татарстан Диния нәзарәте мәгълүматларына караганда, мөхтәсибәтләр арасында беренче өчлекне Балык Бистәсе (256 т), Питрәч (250 т) һәм Сарман (143,5 т) районнары алып тора. Шулай ук Арча (68 т), Балтач (62,9 т), Кукмара (55 т), Әтнә (45 т), Саба (43,12 т), Теләче (42 т), Буа һәм Чирмешән районнары (40ар т) зур активлык күрсәткән.

Татарстан мөселманнары, мохтаҗларга ярдәм итү йөзеннән, республика мәчетләренә яшелчә (бәрәңге, чөгендер, кәбестә, кишер, кабак, ташкабак, суган һ.б.), җиләк-җимеш кайнатмалары, тозлаган кыяр-помидорлар, бал алып килде. Җыелган азык-төлек хәйрия оешмаларына (Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды һәм «Ярдәм» хәйрия фонды тернәкләндерү үзәге), социаль учреждениеләргә (районнардагы картлар йортлары, балалар йортлары), мөселман уку йортларына (мәдрәсәләр, мәктәпләр һәм балалар бакчалары, коръәнхафизлар әзерләү үзәге һ.б.), шулай ук турыдан-туры мохтаҗ гаиләләргә җибәрелде. Гошер җыю кампаниясе Татарстанда барлык мөхтәсибәтләрдә үзәкләштерелгән рәвештә 2017 елдан бирле үткәрелә.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

БРАЗИЛИЯДӘ ЛУЛАЛЫ КИЛӘЧӘК

Планетакүләм вазгыять үзенең киеренке халәтендә калуын дәвам итә. The Economist Америкадагы финанс хәле турында: «Федераль резерв системасы күлдәвеккә утырды», – дип, ачы ирония белән язып чыкты.

Американнарның асларына су керүгә шатланырга була, билгеле. Әмма икътисади хәл бөтен дөньяда авыр. Кытай компартиясе съездыннан соң Күк асты илендә затлы күчемсез милек базары түнде. Байлар, малларын сатып, акчаларын чит илгә күчерә һәм үзләре дә илдән табан ялтыраталар. Синың өченче срогын чин бизнесы шөбһәләнеп кабул итте. Бу хәлләр – глобаль кризисның көчәюе иртәме-соңмы безгә дә сукмый калмаячак. Тагын бер нәрсәне искәртик: якындагы вакытларда Си Цзиньпин Согуд Гарәбстанына сәфәр кылырга җыена. Бу Вашингтонның кытыгына тиячәк. Гарәп – Америка каршылыгы кискенләшергә ихтимал.

Глобаль сәясәтнең шахмат тактасында көчләр чагыштырмасына күпмедер йогынты ясый алырлык вакыйга якшәмбедә Бразилиядә булды. Анда Президент сайлавының икенче туры узды. Гамәлдәге Президент Болсанару элекке башлык, 77 яшьлек сәясәтче Лула да Силва белән бил алышты һәм оттырды. Болсанару – уң карашлы сәясәтче, АКШның элекке Президенты Трамп тарафдары. Байденны яратмый. Шуңа күрә ул агымдагы вазгыятьтә Америкага каршы чыгыш ясаган лидерларның берсе иде. Вашингтонга каршы булгач, автомат рәвештә уенны Россия кырында уйнарга тырышты. Дөрес, Мәскәү өчен артык зур файда күрсәтмәде, әмма хәзерге хәлдә аяк чалмавы да кыйммәткә ия.

Нәрсә генә булмасын, Бразилиядәге тавыш бирү мәгълүмат кырында зур кызыксыну уятты. Газета хәбәрчесенең телефонына сайлау нәтиҗәләре турында беренче хәбәрләр төн уртасында килә башлады. Башта ике кандидатның тигез баруы турында хәбәр итсәләр, бездәге төн таңга авышкач, якындагы ярты сәгать эчендә Лула да Силва Бразилиядәге Президент сайлавында үзенең җиңүен игълан итәчәк, дигән хәбәр килде. Аңлашыла инде: сул карашлы кандидатның җиңүен Куба һәм Венесуэла лидерлары алкышлап каршы алды. «Лула кайтты, Хезмәт ияләре партиясе кайтты, социаль гаделлек кайтачак», – дип белдерде Куба Президенты Мигель Диас-Канель.

«Российская газета» нейтраль бәя бирергә тырышты. Мәскәүдә Лулага да каршы түгелләр, Болсанару да кызганыч. «Йөзләгән кеше, Болсанаруны яклап, Бразилия башкаласы үзәгенә җыелды... Кешеләр елыйлар... Дога кылалар», – дип яза газета телеграм-каналы. Җиңелгән Президент тарафдарларының протестка чыгуы көтелә. Болсанару да үз тарафдарлары белән шундый адым ясарга җыена.

Россиядә

АРТКА ЮЛ ЮК?

Россиядәге вазгыятьне көнбатыш чикләрдәге конфликт билгели. Хәл киеренке һәм бик авыр. Мәскәү Кытайның тышкы эшләр министры авызыннан да үзенең сөйләшүләргә әзер икәнен әйттереп карады. Җавап юк. Атна ахырында җавап урынына илнең Кара диңгез флотына беспилотникларның көчле һөҗүме оештырылды.

Бик күп имеш-мимеш таралды. Флотның флагманы булган фрегат шартлатылу, берничә кораб батырылу турында сүзләр күп йөрде. Әмма Мәскәү боларның барысын да кире кага, җиңелчә генә зыян салынуын, беспилотникларның юк ителүен әйтә. Украина белән «ашлык килешүе»н билгесез вакытка кадәр туктатып тору турында Россия ягының рәсми белдерүе бар. Бу белдерү шулай ук халыкара мәйданда зур яңгыраш бирде. Россия дөньякүләм ачлыкны махсус оештыра, дигән гаепләүләр ява башлады. Мәскәү, һөҗүм итүче беспилотниклар ашлык ташучы кораблардан күтәрелде, дип белдерә. Каршы як моны кире кага, юләрлек дип атый. Россия разведкасы һөҗүмнең Англия ярдәме белән оештырылуы турында фикерне дә алга сөрә. «Төньяк агым» торбаларын шартлатуда инглизләрне гаепләүләр дә ишетелде.

Көнбатыш «ашлык килешүе»нең өзелүен Мәскәүгә каршы байрак итеп күтәрергә җыена. «Дүшәмбе көнне Киев, Әнкара һәм БМО Кара диңгездә 14 корабның (ашлык төягән кораблар турында сүз бара) хәрәкәте турында килештеләр, бу хакта Россиягә әйтелде», – дигән хәбәр килде. Бу Россиядән курыкмыйбыз дигәнне аңлата. РФ Тышкы эшләр министрлыгы илнең «ашлык килешүе»нә кире кайту ихтималы турында уйлый. Министр урынбасары Андрей Руденко: «... моның өчен Севастопольдәге флотка һөҗүмнең барлык шартларын да ачыкларга кирәк», – дигән сүзләр әйтте. Бу очракта Мәскәүгә чигенү отышлырак, билгеле. Хәлне кискенләштерү Россия файдасына түгел.

Американнар яңартылган атом бомбаларын китерүне ашыктыралар. Финляндия, НАТОга кереп беткән очракта, үз туфрагына АКШның атом коралын урнаштыруга каршы булмавын, хәрби базаларны чикләмәячәген әйтте. Петербургка кул сузымы гына ара бит. Вашингтон Европага тагын бер очкыч йөртүче корабтан торган хәрби-диңгез төркемен юллады. Ул Англиянең көньягындагы Портсмуттагы хәрби-диңгез базасына ноябрь урталарына килеп җитәчәк. «Джордж Буш» авианосецы җитәкчелегендәге бер төркем Европа ярларында инде. Бик зур хәрби куәтләр болар.

Россия Президенты Администрациясе җитәкчесенең беренче урынбасары Сергей Кириенко: «Россиягә каршы сугыш киң фронт белән алып барыла: махсус хәрби операция зонасындагы хәрби хәрәкәтләр – аның бер өлеше генә, ә кире кайтарып алып булмаслык тектоник үзгәрешләр чоры башланып килә», – дигән белдерү ясады.

Атна ахырында Үзәк банк җитәкчесе Эльвира Нәбиуллина илдәге икътисади хәл турында сөйләде. Сак оптимизм белән сугарылган булса да, аның чыгышында шатланырлык нәрсәләр юк.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

БУРЫЧ ҮТӘЛДЕ

Татарстанда өлешчә мобилизациягә бәйле бурыч үтәлде. Бу хакта Хөкүмәт йортында узган очрашуда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белдерде.

– Татарстан өлешчә мобилизациягә бәйле Россия Оборона министрлыгы куйган бурычларын үтәде, – диде Президент. – Республиканың чакырылыш комиссиясе шәһәр һәм район башлыклары җитәкчелегендә җирле комиссияләр белән берлектә бик зур эш башкарды.

Шушы көннәрдә чакырылган хәрбиләр башкаладагы хәрби училищеда әзерлек уза. Уку йорты җитәкчесе Кирилл Кулаковка егетләрне кием-салым белән тәэмин итү, әзерлек буенча барысын да югары дәрәҗәдә оештыру бурычы куелды.

Моннан тыш Рөстәм Миңнеханов хәрбиләрнең гаиләләренә ярдәм күрсәтү турында онытмаска кушты.

– Бүген безнең төп бурычларның берсе – хәрби хезмәткәрләрнең һәм мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылганнарның гаиләләрен кайгырту, – диде ул. – Шулай ук һәлак булган хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләре дә аерым игътибар таләп итә. Кабул ителгән карарлар барысы да тулысынча үтәлергә тиеш, моны контрольгә алырга кирәк.

Шунысын да искәртик: халык белән эшләүдә 112, «Ярдәм янәшә!», «Игелекле Казан», «Халык контроле» һәм башка хезмәтләр дә ярдәм итә. «Кайнар элемтә» номерлары эшли. Халыктан 28 меңнән артык мөрәҗәгать кабул ителгән. Аларны кабул итеп, ярдәм оештыру белән 675 волонтер шөгыльләнә. Республиканың 15 югары уку йортында гуманитар штаб ачылды.

«Татар-информ»

Сүз уңаеннан, атна азагында республикадан тагын бер эшелон хәрбиләр озатылды. Бу юлы Казан танк училищесы базасында әзерлек узган ирләр, әтиләр, абыйлар, егетләр китте. Туганнар, якын кешеләр, дуслардан кала, хәрбиләрне озатырга Татарстан җитәкчелеге дә килгән иде. Егетләрне илнең көньяктагы төбәкләренә җибәрәләр.

Республиканың вице-премьеры Ләйлә Фазлыева мобилизацияләнүчеләргә уңышлар теләде.

– Бөтен Татарстан сезнең җиңү белән кайтуыгызны көтә! Без сезгә ышанабыз да, горурланабыз да, – диде ул.

Хәрби хәрәкәтләр вакытында уңышның артыгы булмас анысы. РФ Коры җир гаскәрләренең ракета гаскәрләре һәм артиллерия башлыгы, генерал-лейтенант Михаил Матвиевский да егетләрнең тизрәк әйләнеп кайтуларын теләде. Шәхси состав туплануын, хәрбиләрнең дошман объектларын юк итүгә бәйле әзерлек этапларын узуын хәбәр итте.

Танк училищесы җитәкчесе, генерал-майор Кирилл Кулаков та хәер-фатыйхасын бирде.

– Сез хәзер барыгыз да бердәм көрәш сафында, сез барыгыз да – бер-берегез өчен хәрби туганнар. Бер-берегезгә абый-энеләрегезгә караган кебек карарга тиеш. Иптәшегезгә ярдәмгә килергә әзер булыгыз, бәла-казадан коткарыгыз. Иң мөһиме – командирлар куйган барлык бурычларны төгәл үтәү, – диде ул. – Сезне 1945 елда бабаларыбызны – чын җиңүчеләрне каршы алгандай каршы алсыннар.

Дүшәмбе «Бердәм Россиянең Яшь гвардиясе» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстандагы төбәк бүлеге активистлары Мариуполь шәһәренә гуманитар ярдәм җибәрде. Ярдәм кысасында тушенка, шикәр, он, көнкүреш кирәк-яраклары, ярмалар, канцелярия товарлары җыелган. Болар шәһәр мәктәпләренә җибәреләчәк. Моннан тыш Казан федераль университеты Мариуполь дәүләт университеты өчен 245 методик, 200 укыту дәреслеге, матур әдәбият, җыентык, сүзлекләр дә җибәрде.

ЮГАЛМАСЫН АКЧА

Көтелгәннән яхшырак. Хөкүмәт йортында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашында узган финанс, салым һәм казначылык органнары киңәшмәсендә республика икътисадының бүгенге торышын шулай дип бәяләделәр. Бюджет торышы да канәгатьләндерә. Әмма тынычланырга ярамый.

Быел 9 айда республиканың берләштерелгән бюджетына 362,3 миллиард сум акча кергән. Рөстәм Миңнеханов моны яхшы күрсәткеч дип атады.

– Быелгы нәтиҗәләр шактый уңай. Ләкин без моның белән генә тынычланырга тиеш түгел. Вазгыять теләсә кайсы вакытта кискенләшергә мөмкин. Шуңа күрә безгә катгый финанс дисциплинасын сакларга, беренчел һәм социаль бурычларны тиешенчә башкарырга кирәк, – диде Президент.

Федераль казначылыкның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе Рөстәм Нуриәхмәтов сүзләренә караганда, бюджет керемнәренең 49,5 миллиард сумы федераль казнадан күчкән. «Ел азагына кадәр тагын 26,9 миллиард сум күчәргә тиеш», – диде идарә җитәкчесе.

Татарстан финанс министры Радик Гайзатуллин киләсе ел бюджеты 27 миллиард сумнан артык дефицит белән формалаштырылуын искәртте.

Ел башыннан бирле Татарстанда 1 триллион сум күләмендә салым җыелган. Бу узган ел белән чагыштырганда 18 процентка күбрәк.

– Хөкүмәт органнары белән эшмәкәрлек тармагының нәтиҗәле хезмәттәшлеге тышкы көчләр йогынтысын шактый җиңел кичерергә ярдәм итте. Нәтиҗәдә, Татарстан икътисадтагы катлаулы чорны көтелгәннән дә яхшырак уздыра. Бу бюджетның салым керемнәре белән тулылануына да уңай йогынты ясый, – диде Салым федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе Марат Сафиуллин.

Бүгенге вазгыятьтә мобилизациягә эләгүчеләргә салым ташламалары ясалуын да искәртте ул. Аерым алганда, Ватан алдында бурычын үтәргә киткән егетләр узган ел өчен транспорт салымыннан азат ителә.

Рөстәм Миңнеханов бүгенге шартларда эшмәкәрләргә дә игътибарны арттырырга кирәклеген искәртте.

– Хәзерге катлаулы сәяси вазгыятьтә безнең оешмалар эшмәкәрлекне үзгәртеп кору буенча зур эш алып бара. Бу эш, иң беренче чиратта, комплектлаучы җиһазлар кайтарту тәртибен үзгәртү, импортны алмаштырырлык җитештерү юлларын табудан гыйбарәт. Салым органнары хисабыннан күренгәнчә, оешмаларның чыгымнары 1,6 тапкыр арткан. Шуңа күрә тармак министрлыкларына кыенлык кичергән оешмаларга федераль һәм безнең дәрәҗәдә ярдәм итү юлларын эзләргә кирәк, – диде Президент.

tatarstan.ru

1 октябрьгә Татарстанда салым буенча 12,5 миллиард сум күләмендә бурыч җыелган. Бу алдагы ел белән чагыштырганда 4,6 миллиард сумга артыграк. Салым буенча бурычларның күп өлеше (4,5 миллиард сум) Татарстанның Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына караган оешмаларга туры килә. Салым бурычының 2,7 миллиард сумы – республиканың Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына, тагын 850 миллион сум бурыч Транспорт министрлыгына караган оешмаларда җыелган.

– Кайбер районнарда җир салымы буенча күрсәткечләр кимегән. Бездәге җирләр кимемәде бит. Лаеш, Нурлат, Бөгелмә, Питрәч, Баулы, Азнакай, Зәй, Сарман, Чүпрәле, Алабуга, Менделеевск, Балтач, Мөслим районнары башлыклары, бу эш – сезнең җаваплылыкта, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Президент физик затлардан җыелган милек салымын да, халык арасында аңлату эшләре алып барып, вакытында түләтеп бетерергә кирәклеген искәртте.

ТОТЫП КАРАМЫЙЧА БУЛМЫЙ

Казанда пилотсыз очу аппараты төзү, юл салганда туфракны ныгытучы җайланмалар куллану, терлекчелектә азык аксымына кытлыктан котылу. «Татнефтехиминвест-холдинг» акционерлык җәмгыятенең Директорлар советы утырышында әнә шундый проектлар тәкъдим иттеләр.

Президент Рөстәм Миңнеханов уздырган утырышта компаниянең 9 айлык эшчәнлегенә нәтиҗә дә ясалды. Ел башыннан бирле республиканың нефть-газ химиясе комплексының төп оешмалары җитештерүне 2,9 процентка арттырган. Моңа нефть табу һәм эшкәртү, азотлы ашламалар, пластмасса җитештерүне арттыру хисабына ирешкәннәр. «Татнефтехиминвест-холдинг»ның генераль директоры Рафинат Яруллин сүзләренә караганда, 9 ай эчендә нефть-газ тармагы оешмаларыннан республика казнасына кергән акча, 1,5 тапкыр артып, 94 миллиард сум тәшкил иткән.

Рафинат Яруллин, предприятиеләрнең эшчәнлеге турында сөйләгәндә, химия тармагында фәнни технологияләр юнәлешендә үсешне тизләтергә кирәклеген әйтте. Аның фикеренчә, кирәкле продукцияне тотып карый алмагач, галимнәрнең күп кенә хезмәтләре гамәлгә ашырылмыйча да кала. Тәҗрибә өчен кирәкле продукцияне алу өчен исә бетмәс-төкәнмәс килештерү эшләре аша узарга кирәк. «Илнең икътисади куркынычсызлыгы хәл ителгән шартларда бу эш мөмкин кадәр тизрәк алып барылырга тиеш», – диде Рафинат Яруллин.

Директорлар советы утырышында берничә инновацион проект та каралды. Шуларның беренчесен Мәскәүдәге «Иннопрактика» оешмасы җитәкчесе Дмитрий Зайцев тәкъдим итте. Аның фикеренчә, метаннан биопротеин табып, терлекчелек тармагында азык аксымына кытлыктан котылырга мөмкин. Әлеге ысул белән табылган продуктны фармацевтика тармагында да кулланырга мөмкин булачак, ди белгеч. 2023–2024 елларда бу эшне пилот проект буларак Киров өлкәсендәге «Уралхим» оешмасы базасында гамәлгә ашырып карарга җыеналар. «Мондый азыкны барлык төр малга да ашатырга ярый. Аны шул исәптән кошчылык тармагында да файдаланырга мөмкин», – диде Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров.

Казанда Оборона министрлыгы белән «Россия почтасы» өчен пилотсыз очу аппараты җитештерү эшенә керешәчәкләр. Бу хакта Россия Фәннәр академиясенең циркуляр икътисад үзәге җитәкчесе урынбасары Василий Шестюк сөйләде. Ул Татарстанда югары молекуляр полиэтилен һәм аның нигезендә җепләр җитештерү эшен башлап җибәрергә дә тәкъдим итте. Алар бронежилет белән хәрби каска җитештергәндә кирәк.

Башкортстан Республикасының нефть химиясе эшкәртү институты директоры урынбасары Эльшад Теляшев Әшәлче җирлегендә табылган ябышкак нефтьне эшкәртеп, аннан юл салганда кулланыла торган югары сыйфатлы битум ясарга тәкъдим итә. «Мондый чималдан ясалган битум нык һәм һава торышы үзгәрешләренә дә бирешми», – ди ул. Рөстәм Миңнеханов әлеге тәҗрибәне өйрәнеп, аерым бер участокта сынап карарга киңәш итте.

«Эм-Си Баухеми» ҖЧҖ вәкиле Евгений Журавлев җирне ныгыту өчен кулланылган полимер инъекцияләр турында сөйләде. «Алар, эшне туктатмыйча гына, хәтта эре объектларның нигезен дә ныгытырга мөмкинлек бирә», – ди белгеч. Әлеге алым юл төзегәндә, тотрыксыз туфракта урнашкан сәнәгать объектларын сафка бастырганда аеруча кирәк булырга мөмкин. Бу хакта сөйләшкәндә, Сөембикә манарасының авышып барганын да искә алдылар.

Бер-беребезне белү өчен

3 ноябрьдән 8 ноябрьгә кадәр Россиядә «Зур этнографик диктант» уза. Ел саен үткәрелә торган чарада быел катнашучылар саны тагын да артыр дип көтелә.

Татарстанның мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин әйтүенчә, быел республикада диктант язу өчен 192 мәйданчык оештырыла.

– 2016 елда Россиядә диктантны 90 меңгә якын кеше язса, узган ел катнашучылар саны 2,5 миллионнан артып китте. Былтыр республикада диктантны 30 мең кеше язды. Бу әлеге акциягә кызыксынуның елдан-ел артуын күрсәтә. Быел без бу күрсәткечне ике, хәтта өч тапкыр арттырырга җыенабыз. Акциянең максаты – илебездә яшәүче халыкларның мәдәнияте, гореф-гадәтләре белән танышу, – диде министр урынбасары.

«Татарстан халыкларының яшьләр ассамблеясы» иҗтимагый оешмасы рәисе Тимур Кадыйров әйтүенчә, 4 ноябрьдә «Казан Экспо» күргәзмәләр үзәгендә 600 кеше диктант язачак.

– Диктант җиңел булмаячак. Аны язган кешедә, чыннан да, илебез халыкларының мәдәниятен алга таба өйрәнү теләге туачак, – диде ул.

Диктант биремнәре 30 сораудан гыйбарәт. Егермесе һәркем өчен гомуми булса, унысы аерым төбәкләргә кагылышлы. Аларга җавап бирү өчен 45 минут вакыт бирелә. Дөрес җаваплар акциянең сайтында 11 ноябрьгә кадәр урнаштырылачак.

Казан федераль университетының антропология һәм этнография кафедрасы доценты Елена Фролова фикеренчә, бу чараның асылы – барлык сорауларга да дөрес җавап бирүдә түгел, ә кызыксыну уятуда.

Акциядә катнашу өчен төбәкләрдәге диктант мәйданчыгына килергә кирәк. Андый мөмкинлек булмаган очракта, «Зур этнографик диктант» сайтында (www.miretno.ru) онлайн-тест узарга мөмкин.

Ләйсән САФИНА

АВЫЛНЫ ҮЗГӘРТҮ ҖИҢЕЛ ТҮГЕЛ

Балтач

Үзем күрдем

Кунакларны каршы алырга дип чыккан гармунчыларны күреп, янәшәмдә торган апалардан: «Болар барысы да үзегезнекеләрме соң?» – дип сорадым. «Безнекеләр!» – диде алар, горурланып. Шушы кадәр гармунчысы булган авылда мәдәният йорты ничек буш тора алсын ди инде?!

Моннан 40 ел элек төзелгән мәдәният йорты заманында районда иң зурлардан була. Ике катлы, 320 урынлы. Ун меңнән артык китап фонды булган китапханәдән соң да әле монда спорт залы, авыл советы, почта бүлекчәсе дә сыя. Аларга бераздан ФАП та кушыла. Авылда мәчет ачылганчы бер бүлмәсе намаз уку урыны – мәдрәсә ролен дә үти хәтта. Бер чорда биредә тегү цехы да эшләде дип хәтерлим. Хәзер бик популяр булган күпфункцияле үзәкне, баксаң, Бөрбашта инде моннан кырык ел элек үк төзегән булганнар икән! Быелгы ремонттан соң әле биредә ике музейга да шактый иркен урын табылган.

Хөкүмәт программасы нигезендә үзләренә чират җиткәнне бөрбашлылар шактый озак һәм сабыр гына көтә. Сигез ай барган ремонтның нәтиҗәсе күз алдында: биредә яңартылмаган бер генә урын да калмаган. Бөтенесе сокланырлык дәрәҗәдә. «Мондый ремонт 30–40 елга бер генә була», – диде район башлыгы Рамил Нотфуллин тантанада. Башкаладан килгән кунаклар бу матурлыкның кадерен белергә, саклап тотарга, буш тотмаска чакырса, чара башланганчы ук инде Бөрбаш апалары үзара: «Бигрәк матур булган. Йөрүчесе булса ярар иде. Өлкәннәр – телевизорга, яшьләр телефонга береккән бит хәзер», – дип борчылып сөйләште. Авыл җирлеге башлыгы Равил Галимуллин чыгышы исә аларның барысына җавап булып ишетелде: «Шөкер, авылыбызда башкалар белән чагыштырганда демографик хәл әйбәт, 230лап хуҗалык бар, 800гә якын кеше яши, яшь гаиләләр күп, балалар күп туа. Без елына дүрт Сабан туе гына үткәрәбез, унлап республика күләмендәге чара гына уздырыла…»

Мәдәният өлкәсендә генә түгел, бөрбашлыларның соңгы еллардагы гомуми активлыгы, күпсанлы өмәләр үткәреп, берничә ел рәттән районда иң зур суммада үзара салым акчасы җыйнап та, юмарт эшмәкәрләре ярдәмендә дә авыл тирәсендәге чүплекләрдән матур парклар ясаулары турында без күптән түгел язган идек. Тантанада катнашкан «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Илшат Фәрдиев та: «Без балтачлылардан күп нәрсәгә өйрәндек инде. Бозау үстерүдән башлап, авыл тирәсендә парклар ясауга кадәр. Искитәрлек зур эшләр эшлисез. Үзегез дә – булган халык, эш тәртибегез дә башкаларга үрнәк булырлык. Авылны шушылай итеп үстерү, үзгәртү җиңел эш түгел, бирегә кайткан саен сезнең авыл өчен сөенеп китәм».

– Бөрбашны, Җәлил хәзрәтне кая гына барсак та, бөтен җирдә беләләр, башкалардан аерылып торучы авыл сез, – диде ТР Дәүләт Советы депутаты Камил Нугаев.

Сүз дә юк, туган авылын таныту, үстерү, ныгыту өчен Җәлил хәзрәт көченнән килгәнне дә, килмәгәнне дә эшләде бугай инде. Олыгаеп барган көнендә дә әле дә авыл дип җан ата. Яңартылган мәдәният йортында ачылган – ике, аның буш торган котелныенда ачылган өченче музей да аның идеясе һәм тырышлыгы нәтиҗәсе. Музейлар белән хәзер беркемне шаккатырып булмый кебек. Әмма берсен берсе тулыландыручы бу өч музейда башкалардан үзгә булган өлешләр байтак. Аның беренчесендә авылның дини тарихы күбрәк яктыртылган. Җәлил хәзрәт төзегән авыл шәҗәрәсе биредә иң төп байлыкның берсе, анда сирәк тарихи экспонатлар да бар, шулар янында ук заманча аквариум, хуш ис таратып утыручы мандарин һәм башка затлы гөлләр. Мондый төрлелек башкаларында да бар. Ул, бердән, кешеләрне уйландыру, үткән белән бүгенгене тоташтыру өчен эшләнгән кебек булса да, Җәлил хәзрәт сүз арасында гына аның серен ачты: болары барысы да нәни балаларны, укучыларны җәлеп итү, аларны тарих белән кызыксындыру өчен дә эшләнгән икән. Элекке котельный бинасында ачылган музейда әнә атны җигеп, туарырга мөмкин. Шунда ук заказ белән ясатып кайтарылган «Сталинец» тракторына утыра аласың. Ә стенада – шушы тракторда эшләгән дүрт авылдаш хатын-кызның фотосурәтләре…

Тагын шунысы сөендерә: бу изге эшләрдә Җәлил хәзрәт ялгыз түгел. Юкка гына әлеге тантанада үзенең чыгышын җирлек башлыгы Равил авыл халкына, игелекле гамәлләрдә башлап йөрүчеләргә кулын йөрәгенә куеп рәхмәт җиткерүдән башламады. Шушы авылда туып-үсмәсә дә, әтисенең туган авылында еш кунак булган, әтисе Рафил яшьли вафат булганнан соң да авыл белән элемтәсен өзмәгән Казанда яшәүче эшмәкәр егет Нияз Галимуллин бу исемлектә беренче урында торадыр. Яктыртулы чаңгы юлы ясауда зур матди ярдәм күрсәткән Нияз мәдәният йорты тирәсен тәртипкә китерү, балалар уен мәйданчыгы төзетү, өченче музейны сафка бастыруны да үз өстенә алган булып чыкты. «Мәдәният йортына ремонт 56 миллион сумга төште, Нияз үзе башкарган эшләре турында үзе сөйләр», – дигән иде район җитәкчесе. Тик тыйнак егет: «Балачагым шушында үтте. Бөрбашны бик яратам. Мөмкинлек булганда бик теләп ярдәм итәм», – дию белән чикләнде.

Бу көнне яңартылган авыл спорт залында Ниязның мәрхүм әтисе – Бөрбашның танылган көрәшчесе, гармунчы, теш табибы Рафил Галимуллин истәлегенә балалар арасында көрәш ярышлары да үтте. Җиденче тапкыр үтүче әлеге ярышларның да иганәчесе Нияз иде…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА



НИКОЛАЙ ИВАНОВИЧ ДУНАЕВ (НАИЛ ДУНАЕВ) (03.05.1937–30.10.2022)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының күренекле артисты, Россия Федерациясенең атказанган артисты, Татарстан Республикасының халык артисты Николай Иванович Дунаев (Наил Дунаев) каты авырудан соң 30 октябрь көнне 86 нчы яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Наил Дунаев 1937 елның 3 маенда ТАССРның Зәй районы Әхмәт авылында дөньяга килә. 1961 елда Щепкин исемендәге Мәскәү театр училищесын тәмамлаганнан соң 60 елдан артыграк вакыт дәвамында Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында хезмәт итте. Ул татар театр сәнгатен үстерүгә бәһаләп бетергесез өлеш керткән атаклы «щепкинчы»ларның берсе иде.

Иксез-чиксез актерлык сәләтенә, күпкырлы иҗатка ия булуы аңа тамашачылар күңелен яулаган бик күп сәхнә образларын тудыру мөмкинлеген бирде. Аның Сәйяр (Ш.Хөсәенов. «Әни килде»), Чотбаев (Ч.Айтматов. «Плаха»), Бәхтияр Канкаев (Т.Миңнуллин. «Бәхтияр Канкаев»), Габдулла Тукай (Ә.Фәйзи. «Габдулла Тукай») Мирвәли (Аяз Гыйләҗев. «Өч аршын җир»), Качкинский (Н.Исәнбәт. «Качкыннар»), Җиһанша (К.Тинчурин. «Зәңгәр шәл»), Якуб Акчурин (Т.Миңнуллин. «Без китәбез, сез каласыз»), Ногман (И.Зәйниев. «Мәхәббәт турында сөйләшик») рольләре төрле буын тамашачылар күңелендә мәңгегә сакланачак.

«Гөргери кияүләре» этнографик комедиясе инде күптән Камал театрының визит карточкасына әйләнде. Спектакльнең тамашачыларны әсир итүендә Наил Дунаевның өлеше гаять зур. Ул спектакль режиссерының керәшеннәр тормышы нечкәлекләрен аңлатучы ассистенты булып торуы белән беррәттән, 25 елдан артыграк вакыт дәвамында төп рольне дә башкарды.

1998 елда Туфан Миңнуллинның «Хушыгыз!» драмасында Нурислам роле өчен аңа Габдулла Тукай исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе бирелде.

Наил Дунаев, сәхнә эшчәнлегеннән тыш, рус һәм чит илләр драматургларының пьесаларын тәрҗемә итү белән шөгыльләнде. Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институты профессоры булды, иҗат тәҗрибәсен яшь буынга тапшырып, аларны актерлык осталыгына өйрәтте.

Наил Дунаевның югары дәрәҗәдәге һөнәри осталыгы күпсанлы бүләкләр белән билгеләнде. Болар – Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены, «Фидакарь хезмәт өчен», Казанның 1000 еллыгы истәлегенә», «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы оештырылуга 100 ел» медальләре, Татарстан Республикасы Президенты Рәхмәте.

Наил Дунаев сөекле эшенә иксез-чиксез тугрылыгы, хезмәт сөючәнлеге һәм югары дәрәҗәдәге иҗтимагый бурыч хисе белән аерылып торды.

Сөекле актерның һәм талантлы шәхеснең якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Р.Н. МИҢНЕХАНОВ, М.Ш. ШӘЙМИЕВ, Ф.Х. МӨХӘММӘТШИН, А.В. ПЕСОШИН, Ә.Ә. СӘФӘРОВ, И.Х. ӘЮПОВА, И.Р. МЕТШИН, Р.Г. КӘРИМОВ, И.М. ЕГОРОВ, Ф.Р. БИКЧӘНТӘЕВ

РИШВӘТНЕҢ КУЛЫ ОЗЫН

Татарстан Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенең баш киңәшчесе Салават Рәхимовка ришвәтчелеккә кагылышлы 5 сорау белән мөрәҗәгать иттек.

:: Салават Фоатович, быел коррупциягә каршы көрәш кысасында ничә тикшерү үткәрелде һәм ришвәтчелеккә кагылышлы законнарны бозуның ничә очрагы ачыкланды? Соңгы елларда аларның саны артамы, әллә кимүгә таба барамы?

– Татарстан Прокуратурасы быелгы 9 айда 1032 хокук бозу очрагын (узган елның бу чорында 969 очрак) теркәгән. Шулай да соңгы ун ел эчендә коррупциягә бәйле вазгыятькә эләккән кешеләр саны ике тапкыр кимегән. Сораштыру нәтиҗәләренә караганда, 2010 елда андыйлар саны 21,2 процент тәшкил итсә, узган ел ул – 9,5 процент. Хокук бозуларның күпчелеге керемнәр, чыгымнар, милек турында дөрес һәм тулы булмаган мәгълүмат тапшыру белән бәйле. Нәтиҗәдә, 614 кеше дисциплинар җаваплылыкка тартылган. Шулай ук мәнфәгатьләр кисешүне булдырмый калу һәм җайга салу турындагы законны үтәмәү очраклары да бар. Агымдагы елда шундый 28 очрак теркәлгән. Төрле муниципаль вазыйфаны биләгән затларга кисәтү ясалырга, алар эшеннән азат ителергә, билгеле бер вакыт аралыгында җитәкче урында эшләү тыелырга мөмкин. Шулай да ышаныч югалту сәбәпле эшеннән азат итү иң каты дисциплинар җаваплылык булып тора.

:: Татарстанда кайсы тармакларда коррупция очраклары аеруча зур?

– Агымдагы елда 560 норматив хокукый актта 608 җитешсезлек табылды. Иң күп коррупциоген факторлар кеше һәм гражданинның иреге һәм хокуклары, халыкка муниципаль хезмәтләр күрсәтү өлкәләренә кагылышлы норматив хокукый актларда табылган. 2022 елның 9 аенда республикада коррупция юнәлешендәге 1048 җинаять ачыкланган, аларның 123е аеруча авыр җинаять санала. Аерым тармакларга килгәндә, сәламәтлек саклау һәм социаль тәэмин итү өлкәсендә – 141, мәгарифтә – 55, төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык юнәлешендә – 21, күчемсез милек, шул исәптән җиргә бәйле эшләрдә 18 җинаять очрагы теркәлгән. Моннан тыш, ришвәт алуның – 185, ришвәт бирүнең – 262, әлеге эштә арадашлык күрсәтүнең 98 очрагы ачыкланган. Соңгы биш елда аларның эчтәлеге үзгәрде дип әйтеп булмый. Татарстан түрәләре арасында да ришвәтчелеккә кагылышлы законнарны бозуга бәйле очраклар бар. Быел Татарстан Президентының Ришвәтчелеккә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе шундый 33 тикшерү уздырды. Дәүләт вазыйфасындагы – 5, муниципаль вазыйфадагы – 25, җирле администрацияне килешү буенча җитәкләгән 3 кеше тикшерелде.

«Татар-информ»

:: Коррупция белән очрашкан татарстанлылар тикшерү органнарына еш мөрәҗәгать итәме? Бу мәсьәләдә хокук саклау органнарына ышаныч ни дәрәҗәдә?

– Кеше ришвәт биргән, алган яки бу эшкә катышы булган очракта, үзенә нинди җаваплылык алуын белергә тиеш. Бу мәсьәләгә карата сораштыру уздырылган иде. Катнашучыларның 43 проценты моның закон бозу булуын таный. Респондентларның күпчелеге фикеренчә, ришвәтчелеккә каршы көрәшүдә законны көчәйтергә кирәк. Сораштыруда катнашучыларның 42 проценты исә керем һәм чыгымнарның бүленешен контрольдә тоту да ришвәтчелекнең тамырын корытырга ярдәм итәчәк, дип саный. Хокук саклау органнарының эшчәнлеген көчәйтү дә әлеге күренешкә чик куяр иде, дип уйлаучылар бар. Кешеләр хокук саклау органнарына мөрәҗәгать итәргә каршы түгел. Тик шул ук вакытта респондентларның 56 проценты ришвәтчелеккә каршы чараларда катнашырга әзер булмауларын белдергән. Бу очракта шуңа басым ясыйсым килә: әлеге мәсьәләдә хокук саклау органнары халык белән кулга-кул тотынып эшләгәндә генә тиешле нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин. Шуңа күрә кешеләр ришвәт сорау очракларын белә икән, хокук саклау органнарына курыкмыйча мөрәҗәгать итсен иде.

:: Коррупция очраклары иң еш очрый торган районнар кайсылар?

– Тикшерү нәтиҗәләре күрсәткәнчә, дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәт турындагы закон бозу очраклары агымдагы елның 9 аенда Зәй, Әлмәт, Тукай районнарында күп ачыкланган. Иң азы Арча, Буа, Кама Тамагы районнарында. Шулай да иң күп хокук бозу очраклары әлеге районнарда дисәк, дөрес булмас иде. Бу коррупция һәм башка төрле хокук бозуларны булдырмый калу буенча җаваплы кешеләрнең эше турында сөйли. Министрлыкларга килгәндә, бу юнәлештә иң нәтиҗәле эшләүчеләр – республиканың Җир һәм мөлкәт министрлыгы, Сәламәтлек саклау министрлыгы. Ведомстволар арасында – Татарстанның Тарифлар буенча дәүләт комитеты, Татарстан Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышын күзәтү идарәсе. Ә менә Мәдәният министрлыгы һәм Архив эше буенча дәүләт комитетының активрак булуын телибез.

:: Аерым өлкәләрдә коррупциягә каршы нинди көрәш чаралары күрелә?

– Татарстанда 2012 елдан бирле коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча республика эксперт төркеме эшли. Аның төп максаты – ришвәтчелекне анализлау һәм аның сәбәпләрен ачыклау. Коррупция теләсә кайсы тармакта очрарга мөмкин. Шуңа күрә эксперт төркем җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре, авыл хуҗалыгы, төзелеш, сәламәтлек саклау, халыкка хезмәт күрсәтү өлкәләрендә коррупцияне булдырмый калу буенча эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген өйрәнә. Шулай ук алар муниципаль мөлкәтнең дөрес файдаланылуына, субсидия һәм грантларның үзләштерелүенә һәм башка хезмәтләр үтәлешенә зур игътибар бирә.

Зөһрә САДЫЙКОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Физик культураны һәм спортны үстерүдәге казанышлары, Татарстан Республикасында волейболны популярлаштыруга зур өлеш кертүе өчен «Динамо-Казан» хатын-кызлар волейбол клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы баш тренеры **Гыйлаҗетдинов** Ришат Сираҗетдин улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

«Түбән Каманың 1 номерлы пассажир автотранспорты предприятиесе» акционерлык җәмгыяте автомобиль йөртүчесе **Афанасьев** Илья Васильевичка, «Тулпар Техник» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Дунин** Вячеслав Викторовичка, «Татспецтранспорт» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте Елхов технологик транспорт идарәсенең күтәргеч җайланма машинисты **Фазлыев** Ринат Хаҗип улына, «Альтекс» компанияләр төркеме» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең автобус йөртүчесе (Чаллы шәһәре) **Хәйретдинов** Роберт Әмирҗан улына, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең эксплуатация бүлеге автомобиль йөртүчеләре: **Кузнецов** Александр Михайловичка, **Малов** Николай Ивановичка, **Пренов** Мәхсут Төхтәсин улына, **Сафиуллин** Илдус Наил улына, **Таҗиев** Рөстәм Юнис улына **«Татарстан Республикасының атказанган транспорт хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Белдерү

ИЗВЕЩЕНИЕ о проведении аукционов на право заключения договоров о создании искусственных земельных участков

ГБУ «Республиканская имущественная казна» (организатор торгов, специализированная организация) и Министерство земельных и имущественных отношений Республики Татарстан (уполномоченный орган), руководствуясь Федеральным Законом от 19 июля 2011 г. № 264-ФЗ, во исполнение распоряжений Министерства земельных и имущественных отношений Республики Татарстан от 31 октября 2022 года № 3225-р, 3226-р, 3227-р, 3228-р, на основании Разрешений на создание искусственного земельного участка на водном объекте, находящегося в федеральной собственности, полностью расположенного на территориях соответствующих субъектов Российской Федерации и использование водных ресурсов которого осуществляется для обеспечения питьевого и хозяйственно-бытового водоснабжения двух и более субъектов Российской Федерации, либо на водном объекте (его части), который находится в федеральной собственности и не расположен на территории субъектов Российской Федерации, за исключением случая создания искусственного земельного участка на водном объекте в границах морского порта от 8 апреля 2022 года № 16-004, 16-005, 16-006, 16-007, выданных Отделом водных ресурсов по Республике Татарстан Нижне-Волжского бассейнового водного управления Федеральным агентством водных ресурсов, проводит **2 декабря 2022 года в 10.00 часов** *(время начала торгов может быть скорректировано в ходе проведения аукциона)* по адресу: г. Казань, ул. Вишневского, д. 26, аукционный зал открытый аукцион на право заключения 4 (четырех) договоров о создании искусственных земельных участков на Водном объекте – Куйбышевское водохранилище. Водохозяйственный участок – 11.01.00.001 – Волжский участок Куйбышевского водохранилища от г. Казани до пгт Камское Устье. Код водного объекта: 11010000121412100000010, с планируемым местоположением: Российская Федерация, Республика Татарстан, г. Казань, Волжские поля, Кировский район, акватория Куйбышевского водохранилища.

1. Начальная цена права на заключения договора о создании искусственного земельного участка общей площадью 7 116 кв. м – 785 000 (семьсот восемьдесят пять тысяч) руб. 00 копеек.

2. Начальная цена права на заключения договора о создании искусственного земельного участка общей площадью 7 270 кв. м – 2 546 000 (два миллиона пятьсот сорок шесть тысяч) руб. 00 копеек.

3. Начальная цена права на заключения договора о создании искусственного земельного участка общей площадью 39 175 кв. м – 714 000 (семьсот четырнадцать тысяч) руб. 00 копеек.

4. Начальная цена права на заключения договора о создании искусственного земельного участка общей площадью 25 316 кв. м – 1 424 000 (один миллион четыреста двадцать четыре тысячи) руб. 00 копеек.

Извещения о проведении аукционов, планируемые границы искусственных земельных участков, схемы размещения искусственных земельных участков, создаваемых на водном объекте, проекты договоров о создании искусственных земельных участков, форма заявки, размещены на официальном сайте Российской Федерации для размещения информации о проведении торгов https://torgi.gov.ru/new/public, на сайте Министерства земельных и имущественных отношений Республики Татарстан https://mzio.tatarstan.ru/ в разделе «Аукционы и конкурсы».

По вопросам представления заявки для участия в торгах, получения дополнительной информации обращаться в ГБУ «Республиканская имущественная казна» в рабочие дни с 09.00 до 17.00, в пятницу до 15.45 (обед с 11.45 до 12.30) с 2 ноября 2022 года до 29 ноября 2022 года по адресу: г. Казань, ул. Вишневского, д. 26, 1 этаж, каб. 110б, по тел.: 264-30-81 (внут.: 2-39). Адрес электронной почты: imkazna@mail.ru. Ответственный – Прокофьева Елена Александровна.

Заявка подается путем заполнения ее установленной формы с приложением необходимых документов. Одно лицо имеет право подать только одну заявку.

Спорт

«Ак барс»ның «кара» октябре

12 очрашуда – 9 җиңелү. Татарстанның төп хоккей командасы октябрь аен әнә шундый нәтиҗә белән тәмамлады. Моңа кадәр иң шәп уенчылар исемлегендә йөргән хоккейчыларга ни булган? «Ак барс» тамашачысы шул сорауга җавап көтә. «Нефтехимик»ны җиңү ул әле кризис чоры узды дигән сүз түгел. Бүген Казан командасы ЦСКА белән очраша.

Сентябрьне «Автомобилист»ка җиңелү белән тәмамлаган «Ак барс» көзнең икенче аенда хоккей сөючеләр теленнән төшмәгән командага әверелде. Олег Знарок уенчылары Екатеринбург командасына – тагын өч, «Металлург» белән «Салават Юлаев»ка икешәр мәртәбә оттырды. Ярый хуш, болары Көнчыгыш конференциясенең лидерлары сафында йөри. Тик бит турнир таблицасының аскы өлешеннән күтәрелә алмый азапланган «Трактор» белән «Барыс» та «Ак барс»тан көчлерәк булганнарын дәлилләде.

Сезон башланыр алдыннан «йолдыз»лар белән килешү төзеп, спорт җәмәгатьчелеге теленнән төшмәгән командага ни булган? Моңа кадәр иң нәтиҗәле уенчылар булып саналган хоккейчылар кинәт кенә кәшәкә тота алмаслык, алкага суга алмаслык хәлгә килә алмый бит инде. Баштарак баш тренер Олег Знарок журналистларны бер үк сүз белән тынычландырырга тырышты: барысы да контрольдә, яхшырак булсын өчен эшлиләр. Кайчак журналистлар белән очрашуда артык кызып китсә дә, икенчесендә елмаерга, татарча сүзләр әйтеп, киеренке хәлне йомшартырга тырышты.

Әмма җиңелүләр арта барып, тискәре рекордлар куела башлагач, имеш-мимешләр тагын да артты. Команда уенчылары төркемнәргә бүленгән һәм алар үзара тыныша алмый, хәтта кул күтәрүгә кадәр барып җиткәннәр. Әлбәттә инде, бу сүзләрне кире кактылар. «Әллә ниләр уйлап табалар инде. Берсе яза да, икенчесе эләктереп ала, аннары башлана инде. Хоккей турында уйларга кирәк. Без барыбыз да бергә, шуңа күрә җанатарлар бу хәлдән чыгарга ярдәм итәргә тиеш. Бездә бер генә төркем бар: «акбарсныкылар». «Знарокныкылар», «Билалетдиновныкылар», «Мәгановныкылар» дип атасагыз да була», – диде команданың иң тәҗрибәле уенчыларыннан берсе Артем Лукоянов.

Казан командасында барысы да тыныч, дип ышандырырга тырышсалар да, узган атнада булган бер вакыйгага игътибар итми мөмкин түгел. Уфада «Салават Юлаев»ка оттырганнан соң команда автобусына җанатарлар килеп керде һәм хоккейчыларны уйнарга, алка кертергә өндәде. «Без сезнең өчен янган кебек яныгыз!» – дип кычкыра җанатарларның берсе социаль челтәрләрдә таралган видеоязмада. Тегеләре исә артык игътибар итми. Иң гаҗәбе, җанатарларга автобуска керергә баш тренеры Олег Знарок рөхсәт биргән икән. Димәк, уенчыларга ул әйткән сүзләр генә җитми булып чыга?

Ахыр чиктә «Ак барс»ның капитаны, 23 очрашуда нибары 4 алка кертә алган Вадим Шипачев җанатарлар алдында гафу үтенергә мәҗбүр булды. «Барысын да төзәтергә тырышабыз. Җанатарлар күптән түзә инде, тагын бераз сабырлык сорыйбыз. Сез безгә кирәк, – диде ул. – Төрлечә уйнап карыйбыз, тик килеп чыкмый. Командада хәлнең авыр икәнлеген, аның үзеннән-үзе бетмәсен барысы да аңлый. Бу авырлыкларны бергәләп җиңәргә кирәк. Һәркем эшне иң элек үзеннән башларга тиеш», – диде ул. Уенчылар арасындагы мөнәсәбәтләр тыныч икән, әллә эш тренерлардамы? Олег Знарок турында да хәбәрләр күп булды. Мәскәү журналистлары сүзенә ышансаң, баш тренер вазыйфасын Зиннәтулла Билалетдиновка тәкъдим итеп караганнар, әмма ул баш тарткан. Команданың генераль менеджеры Марат Вәлиуллин исә Олег Знарокка ышануларын берничә мәртәбә кабатлады, аны җибәрү турында уйлап та карамаганнар хәтта. Баш тренер үзе команданың уены өчен борчылып, төннәр буе йокламаганын әйтә.

Остазларга кагылмыйлар икән, димәк, составта үзгәрешләр булырга мөмкин. Даниил Тарасовның, әйтик, инде күптән бозга чыкканы юк. Тамашачы, дөресен әйткәндә, аның каядыр китеп баруына артык борчылмаячак та. Ә менә команданың лидеры булырга тиешле Александр Радуловның составтан алынуы узган атнада КХЛда төп вакыйгаларның берсенә әверелде. Олег Знарок әйтүенчә, «Ак барс»та кагылып булмый торган уенчылар юк. «Без аңа ял итәргә мөмкинлек бирдек. Ул үз эшенең остасыдыр дип өметләнәм», – диде баш тренер уенчының бу вакыйганы ничек кабул итәчәге турындагы сорауга. Ә бер көн узуга спорт басмаларының берсендә Радулов белән әңгәмә пәйда булды. Ул анда ни өчен нәкъ менә аны составтан чыгаруларын аңлап бетермәвен әйткән.

Лидерлар әнә шул рәвешле бер-берсен аңламый, бүгенге шартларда халыкның күңелен күрү өчен икеләтә тырышырга кирәклегенә төшенә алмый азаплана. 18 яшьлек сакчы Кирилл Евсеев исә «Нефтехимик» капкасына ике алка кертеп, команда тарихында мондый уңышка ирешкән иң яшь уенчы булып танылды. Әмма бүген ЦСКАга каршы узасы очрашуда аларның гына тырышлыгы җитмәячәк. Ноябрь ниләр алып килер?

КӨНЧЫГЫШ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

	команда	уен	очко
1	Металлург	24	37
2	С. Юлаев	23	33
3	Автомобилист	24	31
4	Сибирь	25	30
5	Адмирал	24	27
6	**Ак барс**	**23**	**24**
7	Авангард	24	23
8	Барыс	25	23
9	Трактор	25	23
10	Нефтехимик	24	19
11	Амур	23	18

ak-bars.ru

РӘҖӘПНЕҢ ГАҖӘЕП КЕШЕСЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Безнекеләр

Хезмәттәшебез Камил СӘГЪДӘТШИН берьюлы ике бәйрәм ясады: 75 яшьлек юбилей һәм «Суд залыннан» китабын тәкъдим итү кичәсе. Тагын берсен өстәсәк тә була: «Ватаным Татарстан» газетасында эшли башлавына – 30 ел.

Китапның исеме тәэсир итте, ахры, уйланып утыра торгач, азрак хәтер дә яңарып китте. Татарстанны иңләп-буйлап, озак еллар буена авыл хуҗалыгы темасын яктырткан журналист остарып беткәндер, күрәсең: кайда гына булса да, хуҗалык эшләренең кимчелекле якларын күрми калмый иде. Озак уйлап тормый, язып та чыга. Тәнкыйть кәнфит түгел бит, шуннан Камил абый утырган кабинет түбәндә алып гәүдәле ир-атлар күренгәли башлый. Туксанынчы еллар шаукымында бу бигрәк тә шулай булды. Тыныч сөйләшә иде ул үзе. Әмма «кунак»ка килүчеләр арасында кабинетта үзе генә бит. Күңел барыбер тынгысызлана. Аптырагач, телефоннан шалтыратып: «Камил абый, хәлең ничек соң синең?» – дип сораша идек.

Газета укучылар белә инде, «Суд залыннан» рубрикасы «Ватаным Татарстан»да күптәннән үзенең саллы урынын алган. Зал дигәч тә, монда һич кенә дә процесс бара торган урын гына күзаллланмый. Журналист җинаятьчеләрнең үзләре белән дә күзгә-күз карап сөйләшкән, кайчакларда иректән мәхрүм итү урыннарының авыр капкаларын да ачып кергән. Язмаларның һәрберсе уйланырга мәҗбүр итә: мондый хәлгә тарымас өчен нишләргә? Кем белә, газетадагы язмалар, бәлки, бик күпләрне ялгыш адымнан саклап та калгандыр.

Камил абыйның юбилей кичәсе бик үзенчәлекле үтте. Күп һөнәр иясе буларак, аның өчен сәхнәдә рәхәт кенә бер «тарткалаш» барды. Кичә Язучылар берлегенең Тукай клубында оештырылгач, аның беренче чиратта язучылыгын, шагыйрьлеген алгы планга куярга тырыштылар. «Каләмдәшебезнең шигырь җыентыклары күп. 50дән артык популяр җыры бар. «Суд залыннан» китабы белән ул прозаик буларак танылды. Чөнки мондагы язмалар нигездә документаль булса да, язылышы әдәби әсәргә бик якын», – диде бу җәһәттән Татарстан Язучылар берлеге урынбасары Рифат Җамал. Без бу сүзләргә бик шатландык. Газетада чыга торган язмаларга әйбәт бәя дигән сүз бит бу.

Әмма ничек кенә булмасын, хезмәттәшебез безгә журналист буларак кадерле. Сәхнәгә кем генә күтәрелсә дә, аның чын авыл хуҗалыгы белгече булуына басым ясамый калмады. Ничәмә-ничә еллар буена кыр-басулардан кайтып кермәгәч, һәр яңалыкның төбенә төшәргә тырышкач, гаҗәп тә түгел кебек инде. Камил абыйның эшен дәвам иттереп, бу теманы алып баручы хезмәттәшебез Зөһрә остазына бигрәк тә рәхмәтле булуын әйтте. Габделбәр Ризванов исә, гадәттәгечә, төрле кызык-мызыкларны искә төшереп мәш килде. Белми дә йөргәнбез, хезмәттәшебезнең «шагыйрь» дигән кушаматы да бар икән. Аңа аны Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Ренат Ибраһимов кушкан. Җырчы аның белән гел очрашу җаен эзләгән. Баксаң, заманында Камил абыйның шигырьләре аша татар телен камилләштерергә теләгән булып чыкты. Сәнгать кешеләре белән гел юлы кисешеп торган хезмәттәшебезнең. Салават Фәтхетдинов иҗатына багышланган сигез китаптагы шигырь юллары да аныкы. Җитмәсә, 8 Март бәйрәмендә дүртьюллыклар багышлап, редакция кызларының да күңелләрен күтәрә белә ул.

Үзенә зыян килсә килә, әмма башкаларны ташламый, ярдәм кулы суза торган гадәте бар хезмәттәшебезнең. Бу җәһәттән тәрҗемәчебез Валентина Семенова да бер вакыйганы искә төшерде: «Камил абый үзе хәтерләми дә торгандыр әле. Ул мине эшкә урнаштырды», – диде ул. Баксаң, ул вакыттагы редактор ни сәбәпледер аны алырга теләмәгән. Шулвакыт әллә кайдан гына килеп чыккан Камил абый, Валяның кем икәнен дә белмичә, бу кызның редакциягә бик кирәклеген, аннан башка эш бармаячагын дәлилли алган. Иң мөһиме, сүзләре дөрес тә булып чыккан.

Камил абыйның туган ягы Спас районыннан килгән кунаклар, мөгаен, барыбыз өчен дә үрнәк булгандыр. Менә ичмасам бер йодрык булып, бер-берсенең кадерен белеп яшиләр, дигән фикер калды тамашачыларда. Тирәнрәк уйлап карасаң, мондый мөнәсәбәт тә җиңел генә бирелми. Камил абый үзе дә бик күп еллар буе ике араны бер итеп йөри. 2000 елда аны якташлар оешмасы рәисе итеп сайлап куйдылар. 25 ел буена район башлыгы вазыйфасын алып барган Камил Нугаев хәзер дә гаҗәпләнә. «Очрашуларны оештырып, безне мәдәният йортларына кунакка гына чакыра иде. Ничек шулай булдыра алган ул аны?» – ди. Шул ук вакытта азрак зарланып алуны да кирәк дип тапты. «Бервакыт шулай «Ватаным Татарстан»ны укып утырам. Районыбызны терлекчелек буенча тәнкыйтьләп чыкканнар. Авторына күз салсам: Камил Сәгъдәтшин. Ачу килде инде үзе. Әмма аннан һич кенә дә качып котылып булмый иде шул. Дөреслек дигәндә, үзебезнеке дип тә тормый ул». Хезмәттәшебез «Иске Рәҗәп авылының мактаулы гражданины» исеменә дә лаек булды бу көнне. Шул уңайдан шаярып та алдылар. Бу таныклык белән аңа туган авылы юлларында бушлай йөрергә, җәй көне җиләк ашарга, гөмбә җыярга ярый икән. Ә менә утка, суга, газга барыбер түлисе, ди.

Камил абыйның авылга кайтасылары бар әле. Ул анда укучылар белән гел очрашып тора. Аларны журналистика серләренә төшендерә. Үзе дә бит авылдашы, танылган журналист Сәмигулла Хәйретдинов оештырган түгәрәктә каләмен чарлый башлаган. Мәктәптә укыган вакытта ук колхоз рәисенең кирәген бирде ул, дип көлдереп тә алдылар. Бәләкәй чакта ук тормыш тәҗрибәсе бай булгандыр, мөгаен. 11 балалы гаиләдә әтиләреннән үрнәк алып үскән малай бит ул. Әтисе турында сүз чыккач, бер кыйссаны да искә төшерик әле. Егерме беренче елгы ачлыктан качып, Камил абыйның әби-бабалары, 20ләп туганы (әтисенә ул вакытта 9 яшь була) Төркиягә юл тота. Чиккә җиткәндә, малайны тиф аяктан ега. Соңрак килеп алырбыз дип ниятләп, баланы калдырып китәргә мәҗбүр булалар. Әмма, ни кызганыч, тора-бара бер-берләрен югалталар. 9 яшьлек малай 5 ел буена Төркия чигеннән туып-үскән Иске Рәҗәбенә таба атлый. Кайтып җиткәндә инде аңа 14 яшь була. Менә нинди нык нәселдән ул Камил абый. Бу хакта күрше авылларда да беләләр, якташларын көтеп торалар. Бүген бушап калган Ирек авылы халкы да чыкты котларга. Алар ел саен җыелышып кайталар, зиратны карап, чистартып, әрвахларга дога укып киләләр икән. Хәзер инде, тарихта калсын дип, авыл турында китап язу уе белән яналар. Камил абый аларга булышырга сүз биргән.

Үзе дә яза, башкаларны да өйрәтә. Берничә ел элек ул булачак журналистлар өчен үз премиясен дә булдырган. Моның өчен КФУ профессоры Васил Гарифуллин белән бергәләп студентлар арасыннан «иң-иң»нәрен сайлап алалар. Ул үзе гади генә: «Үзем укыганда, матди як ифрат авыр булды. Иш янына куш булыр шунда», – дип кенә куя. Әмма алай гына түгел, мондый игътибар беренче чиратта иҗат итәргә стимул бирә. Иҗат кешеләре өчен бу – бик кирәкле әйбер. Камил абыйның туган авылы турындагы «Болгарым-Рәҗәбем» дигән җырына (Сафьян Ибраһимов көе) клип төшереп, якташлары тагын бер зур бүләк ясадылар. Бу хәлләрдән соң Камил абый да тагын да рухланыбрак иҗат итәр дип уйлыйбыз. Исән-сау булып, имин тормышта, балаларының, оныкларының игелеген күреп яшәсен дигән теләктә калабыз.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ЯШЬ ФЕРМЕР ШАМИЛ ӘЮПОВ:

«АВЫЛНЫҢ КИЛӘЧӘГЕ – БЕЗДӘ!»

Актаныш

Росстат мәгълүматларына караганда, Татарстан халкының нибары 23 процентка якыны гына авылда яши. 2019 елда республика авылларында нибары 900 мең кеше яшәгән. Кызганычка, бу сан ел саен 100 меңгә кими бара... Гәрчә соңгы елларда «татар авылы» дигән феноменга игътибар артса да, җитәкчеләр әлеге тискәре күренешнең көчәюен гап-гади итеп аңлата: авыл җирендә эш юк...

«Бер карасаң, сәер бит: ничек инде авылда эш булмасын? Гомумән, авылның язмышын анда яшәүче кешеләр үзләре яза». Актаныш районының Татар Суыксуы авылында яшәүче яшь фермер Шамил Әюпов авыл турындагы уйлануларын әнә шул рәвешле ике җөмләгә сыйдырып бетерде. Дөрес, артык фәлсәфә куертып торырга вакыты юк аның: басу-кырларында эш көтә.

Авыл кешеләренең пай җирләрен арендага алганнан бирле, Әюповларның зур гаиләсендә иртә таңнан кичке караңгыга кадәр туктаусыз эш кайный. Мунчала куагындагы басуга тирес кертәсе, Ак такта басуын сөреп, иген чәчәсе, Көләгеш ягына көтү куасы, ул арада тракторның маен карап, чәчүгә әзерләп куясы, ягулык кайтартасы һәм тагын бихисап эшләр исемлеген яңадан карап чыгасы...

– Авылда эш бетми, ферма хуҗалыгында бигрәк тә. Марттан башлап ноябрь азагына – беренче карлар ятканга кадәр эш тә эш инде. Яз көне чәчүләр, бәрәңге утыртулар, җәй көне печән эшләү, язын чәчкән әйберләрне бөҗәкләрдән саклау, җыештырулар, көз көне бәрәңге алу, җир эшкәртүләр, киләсе елга әзерлекләр булса, кыш көне эш әзрәк, әлбәттә, бу вакытта ремонт белән шөгыльләнәбез. Яшьләрнең шәһәргә омтылуларына тыныч карыйм мин: авылда эш таба алганы кала, әлбәттә. Монда эш җиңелләрдән түгел, шуңа күрә күбесе шәһәрне сайлый инде. Авылларның да төрлесе бар бит: зуррак авылларда мөмкинлекләр дә тудырылган. Аннары соң шунысы да бар: авылда яллар юк диярлек, – диде Шамил.

Бүген Шамил студент кына әле. Ул Казан дәүләт аграр университетында белем ала. Кыр батыры укуда да сынатмый: югары уку йортының мактаулы шәкерте ул. Күпләр югары белем алып, җылы урыннарга өмет иткәндә Шамил авылга кайтырга, фермерлык эшен дәвам итәргә ашкынып тора. Аның максаты – фермерлык династиясенең җепләре өзелмәсен. Чөнки ул – өченче буын фермер, дүртенче буын механизатор.

– Киләчәктә авылда калу нияте белән яшим, әлбәттә. Авылның киләчәге без – яшьләрдән тора инде, – диде Шамил. – 40 мең һөнәр арасыннан үзем сайлаганына тугрылыклы булып калам, җиргә, техникага берегеп үскән егет мин.

Шамил алты яшеннән уенчык түгел, ә чын машина белән уйнап үсә. Әле бакчага йөрер яшьтә генә булса да, әтисе аның техникага һәвәслеген күреп, үзе белән эшкә ияртеп йөри башлый. Умырып ипиен, чумырып ашын ашаган малайның беләгендә җитәрлек көч-куәт, ә иң мөһиме, күзләрендәге дәрт-очкынны күреп, әтисе аңа катлаулы эшләрне ышанып тапшыра. Кечкенәдән үк машинаның һәр детален белеп, күреп үсә, ватылса, төзәтә, трактор-машиналарны сүтеп җыярга да курыкмый. 120 га җирдә печән әзерләп, аның белән күрше-тирә авылларны тәэмин итсәләр, 50 га җирдә икмәк, 20 гектарда бәрәңге үстереп, авыл, шәһәр халкын ел буе ризык белән тәэмин итеп торалар. Фермер булу, үз хуҗалыгыңны тоту – авыр, тынгысыз һәм күп чыгымнар сорый торган хезмәт. Шулай булса да, алар зарланмыйлар, үз көчләре белән тырышып, күптөрле авырлыкларны җиңеп, хәл итеп эшлиләр.

Фермерлык – авылның тоткасы. Җирдә эшләү – бер нәрсә, ә бит уку – югары белем дә кирәк. Шамил читтән торып магистратураны бетерергә, берничә һөнәргә төшенеп, укуын тәмамлаганнан соң, ата-бабалары эшен дәвам итеп, яңалыклар кертеп, авыл хуҗалыгы алдында торган төрле мәсьәләләрне чишәргә җыена.

Ә Актаныш районы Татар Суыксуы авылында яшьләрнең шәһәрләргә китүе бераз тукталды, дияр идем. Авыл җирендә дә үз эшеңне башлап, керем алырга була. Теләк кенә кирәк! Авылда шәхси эшен башлаучылар шактый. Алар арасында яшьләрнең дә күп булуы куандыра. Яшьләр эштән курыкмый, башлаганын ахырына кадәр җиткерә. Кемнәндер өмет итеп, нәрсәдер көтеп ята торган заман түгел. Фермер булсынмы ул, кошчылык, игенчелек белән шөгыльләнүче яисә башка юнәлештә үзмәшгульлеген булдыручымы – тырыш хезмәт кенә көткән нәтиҗәне бирә. Татар Суыксуы авылы халкы борынгыдан эш сөючән һәм һөнәрле булулары белән аерылып торган. Шамил кебек яшьтәшләрем булганда, авыллар гөрләп яшәр әле!

Камилла СИРАЕВА,
КФУның 1 нче курс студенты

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6697 данә
Гомуми тираж – 15337 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 361

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).

16+